**Югары Кәминкә мәктәбенең 2018-2019нчы уку елы өчен отчеты**

Югары Кәминкә төп гомуми белем мәктәбендә үткән уку елында 35 укучы белем алды. Укучыларның барысы да класстан класска күчерелде. Укучылар өчен мәктәптә барлык шартлар да тудырылган. Мәктәптә 14 укытучы эшли, шуларның 2 се читтән килүчеләр (внешние совместители). Берсе яшь белгеч. Укытучылар барысы да югары белемле, 11 е беренче категорияле. Быел янә 2 укытучыбыз үзләренең категорияләрен дәлилләделәр.

Быелгы уку елында 30 бала белем ала. Үткән уку елында 9 сыйныфны 6 бала тәмамлады, 2 се башка мәктәптә укыйлар, 1нче сыйныфка 3 укучы укырга керде.Укучылар мәктәп ашханәсендә 2 тапкыр тукланалар. 7.82 тиен дәүләт бирә. Ә айга эти –әниләрдән туклану өчен өстәмә рәвештә 300 сум акча җыела. Акчалар барысы да банк аша үтәләр. Продуктларны поставщиклар китерә.

9 сыйныфның имтихан нәтиҗәләренә килсәк, укучылар барысы да имтиханнарын яхшы билгеләргә тапшырдылар. 6 укучының 4 се укуны “4” һәм “5” билгеләренә генә тәмамлады. Мәҗбүри имтихан нәтиҗәләре; математикадан сыйфат-100%., рус теленнән сыйфат түбәнрәк -33.3%. Сайлап алу имтиханнары буенча нәтиҗәләр: Химияне 2 укучы тапшырды, икесе дә “4” ле, сыйфат100%, физика ны шулай ук 2 укучы тапшырды , икесе дә “4”, җәмгыять белемен 5 әү тапшырдылар. 4 сенең “4”, берсе “3”, сыйфат 80%, биологияне 3 укучы тапшырды 1се “5”, 2 се “4”, сыйфат 100%. Имтихан нәтиҗәләре алдагы уку елына караганда әйбәтрәк, димәк, алга китеш бар. Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: укучының үзендә укуга теләк булса, имтиханга әзерләрлек белгечләр бар безнең мәктәптә.

Калган укучыларның да мәктәп рейтингын күтәрүдә уңышлары бар. Быелгысы уку елында уңышка ирешкән берничә күрсәткечне әйтеп китәсем килә: математика буенча Республика күләмендә үткәрелгән Эверест олимпиадасында 4нче сыйныф укучысы Шамсутдинова Ралинә призер булды, 6нчы сыйныф укучысы Газимова Асылъяр “Җәлил укулары” конкурсында Бөгелмә шәһәрендә оештырылган зона этабын үтеп

Республикага чыкты, 4нче сыйныф укучылары Шамсутдинова Ралинә, Альмеева Сиринә район күләмендәге "Мастерская Деда Мороза" конкурсында икенче урынны алдылар. Әле уку елының күп агы алда, шуңа да икенче яртыеллыкта уңышларыбыз булыр дип өметләнәбез.

Укучылар белән беррәттән укытучылар да төрле конкурсларда катнаша. Үткән уку елында Вильданова Ф.И. "Классный руководитель года" конкурсының муниципаль этабында лауреат булды. Инглиз теле укытучысы Мисбахова Лилия "Учитель года -19" конкурсының зона этабында җиңеп Республика күләмендә катнашты.

Уку белән берлектә мәктәптә төрле тәрбия чаралары да үткәрелә.Инде традиөиягә әйләнгән "Өлкәннәр көне","Укытучылар көне","Әниләр бәйрәме","Яңа ел бәйрәме" һ.б.ш. бәйрәмнәр зур күләмдә үткәрелде.Тимурчылык эше бүгенге көндә дә балалар һәм өлкәннәр өчен кирәкле гамәл.Укучыларыбыз олы яштәге өлкәннәргә даими булышып, хәлләрен белешеп торалар. Каникул вакытларында да укучылар мәктәптә. Кышкы каникул вакытында Елховой авылына музейга экскурсиягә бардылар, башлангыч сыйныф укучылары саф һавада төрле уеннар уйнадылар, тау шудылар. Шул ук вакытта предметлар буенча консультацияләр дә үткәрелде.

Балаларның ял вакытларын кызыклы һәм файдалы үткәрү максатыннан , ел саен мәктәптә "Бәхетле балачак" мәктәп яны балалар лагере эшли. Анда 20 бала ял итә.Лагер укучыларга бик ошый.Укучылар ялны файдалы хезмәт белән бергә алып баралар. Дару үләннәре җыялар,өлкәннәргә шефлык итәләр.

Мәктәбебезнен территориясе 2 га. Анда иртә яздан башлап көз ахырына кадәр эш кайный. Бу эшләрдә барлык коллектив,укучылар актив катнаша. Яз көне бакчабызда түбәндәге культуралар утыртылды:

| Исеме | Мәйданы(сот.) |
|---|---|
| Бәрәнге | 14 |
| Суган | 6 |
| Орлык суганы | 2 |
| Кишер | 3 |

| | |
|---|---|
| Чөгендер | 1 |
| Помидор | 1 |
| Кыяр | 0,5 |
| Кәбестә | 0,5 |
| Кабачки | 2 |
| Төрлесеннән | 3 |
| Барлыгы | 31 |
| | |

Мәктәп яны участогыннан алган продукцияне мәктәп ашханәсендә укучыларга туклану очен кулланабыз, калган өлешен сатабыз. Мәктәп яны участогыннан жыеп алынган 1100 кг суганнын 900 кг сатып 13500 сум, 300 кг. кишерне урнаштырып 4500 сум остәмә табыш алдык. 2015 елда бастырылган теплицадан гына да 2018-2019 уку елында рассадалар сатып, 10350 сум акча эшләдек.

Теплицадан кергән табыш (рассада)

| Наименование | Кол-во шт | цена | Сумма |
|---|---|---|---|
| Томаты | 375 | 20=00 | 7500=00 |
| Капуста | 50 | 5=00 | 250=00 |
| Перец сладкий | 60 | 15=00 | 900=00 |
| Петуния | 50 | 15=00 | 750=00 |
| Бархатцы | 30 | 15=00 | 450=00 |
| Астры | 50 | 10=00 | 500=00 |
| Всего | | | 10350=00 |

Киләсе ел өчен орлык материалын да әзерәп куйдык: суган, бәрәнге, кишер, чөгендер , помидор орлыклары житәрлек күләмдә саклауга куелды.

2018-2019 уку елында мәктәп яны участогыннан барлыгы 28350 сум остәмә табыш алдык, шул суммадан мәктәп ашханәсенә суыткыч алдык, бер олешен класстан тыш чаралар үткәрүгә, балаларны бүләкләүгә тоттык.

Ел дәвамында “Чисто село начинается с тебя” акиясендә укучыларыбыз актив катнаша. Укытучылар, укучылар, әти -әниләр барысы да тырышып тырышып макулатура, пластик җыялар. Атна саен линейкада кем күпме макулатура, пластик алып килүе турында отчет ясала. Ә нәтиҗәләрен ярты елга бер чыгарабыз. Макулатураны кг 5 сумнан, пластикны 15 сумнан тапшырабыз. 2019 елда 3011 кг макулатура җыелып, шуның 2471кг тапшырылды. Бер укучыга 77,2 кг. Алынган сумманың 66% кызыксындыру максатыннан укучыларга акчалата премияләр итеп бирелде, калган өлеш төрле бәйрәмнәргә, конкурсларга тотылды.

2019 елда бер укучыга 3.3 кг исәбеннән 137,8 кг пластик җыелды. Шуның 132 кг тапшырылды.

Иң күп макулатура тапшыручы класс -2класс (519кг)

Укучылар- Шамсетдинова Рания,2кл-249кг , Газимов Сәяр,2кл-234кг.

Иң күп пластика тапшыручы класс-2класс (52кг)

Укучылар –Газимов Сәяр,2кл (39кг),Шамсетдинова Рания,2кл-13кг.

Мәктәп коллективыбыз кечкенә булуга карамастан,барлык чараларда актив катнашырга тырышабыз.Авылыбызда яңа йортлар салына, димәк, киләчәккә өметебез бар. Республикакүләм оптимизация барган елларда, мәктәбебез саклансын иде. Чөнки авылның киләчәге балаларда. Шаулап торган мәктәбе, балалар бакчасы, мәдәният үзәге булганда гына авылларда яшәеш булачак. Киләчәктә безнең мәктәптә капиталь ремонт булыр дип өметләнәбез әле.